

## **Хәлиуллин Габдулла Хәлиулла улы**

## **1904 -1945**

1941 елда Ленинград фронтында разведчик була.

Ленинград блокадасы беткәнче Ленинградны саклауда катнаша. “Кызыл йолдыз” ордены белән бүләкләнә. 1945 елның февралендә геройларча вафат була






Балалар керделәр утларга,

Балалар сүз бирде тупларга,

Күпләре төренеп шинельгә,

Калдылар еракта йокларга...

Р.Әхмәтҗанов.

Сугыш! Җанга тынычсызлык бирә торган, күңелгә ятышсыз сүз. Сугышлар дөнья яратылганнан бирле булып торган. Сугышлар нәтиҗәсендә дөньяда үзгәрешләр булган. Төрле системада яшәү барлыкка килгән. Җиңгәннәр хуҗа булган, җиңелгәннәр коллар дәрәҗәсендә калган. Ләкин сугыша – сугыша булса да, кешелек җәмгыяте үсешкә дә ирешкән. Бер-берсенә каршы булган капитализм һәм социализм дигән система барлыкка килгән.

Башында Рудольф Гитлер торган немец фашистларының социалистик нигезгә корылган СССР га яки Совет иленә каршы сугыш башлавының максаты бер яктан социалистик системаны юкка чыгару булса, икенче яктан бөтен дөньяда немец халкын гына хуҗа итеп калдыру була.

Дөньяда 200 дән артык төрле милләт яшәү һәм һәр милләтнең яшәргә хокукы барлыгын тоюы, бәлки бу сугышның бөтендөнья сугышына әйләнүенә сәбәпләрнең берсе булгандыр. Социализм нигезендә бөтен милләтләр тигез, бер-берсенә дус, туган дип карала. Милләтләр арасындагы тигезлек аларның нинди милләттән икәнлегенә карап түгел, алар нинди байлыкка ия булуларына карап бүленә. Җитәкчеләрне милләт түгел, идея бердәмлеге берләштергән.

1941 ел.22 июнь. Икенче бөтендөнья сугышы башланган көн. Ил башында И.В. Сталин булган хәлдә СССР дип 16 республиканы берләштергән гигант ил социализм төзү юнәлешендә эш алып бара һәм көннән – көн яңа

үрләр үрләп капиталистик системага караганда үзенең өстенлеген күрсәтә. Гитлер Германиясе белән бер-берeңә каршы сугышмаска дип төзелгән 10 еллык солых нәтиҗәсендә Сталин тыныч яши, һәм разведка мәгълүмәтләренә дә ышанмыйча, каршы тору хәзерлеген күрми һәм нәтиҗәдә Совет халкы күп югалтуларга дучар була.  Кинәт башланган сугышка  бөтен Совет иле халкы бердәм  күтәрелеп, бер сафка баса. Үз теләкләре белән сугышка җибәрүне сорап яшьләре кермәгән балалар да гариза язалар һәм күбесе теләгенә ирешә. Аяусыз сугыш башлана.   Мин сугыш китергән авырлыклар, ачлык, ятимлек турында әбием, әти-әниләрем сөйләгәннәр буенча гына беләм. Чөнки безнең буын тынычта яши.  Сугышта әтиләрен югалткан әниемә хәзер 75 яшь, аның апасы 83 яшьтә, сеңлесенә 72 яшь. Алар сугыш нәтиҗәсендә үзләре кичергән авырлыкланы сөйләгәндә күңел тулып, күзләргә яшь килә.

Минем әтиемнең әтисе Йосыпов Мөксин сугыш башлану белә үк сугышка китә һәм шул ук елны вафат була. Икенче бабам - Халиуллин Габдулла (әниемнең әтисе) җаваплы эштә булу сәбәпле, сугышка 1942 нче елның 22 мартында китә. Бабамның сакланган бердәнбер фотосы сугыш кырыннан җибәрелгән фото. Бабамның туган елы – 1904 нче ел.  Аңа быел 110 яшь булыр иде. Ә ул инде 70 ел җир куенында ята.

Бабам сугышка киткәндә 35 яшьлек әби 4 бала белән бик авыр тормышта ятим кала. Иң кечесенә әле 2 айдан артык кына була.  Бабай хатларын бик еш яза.

Башта ул Ленинград фронтында разведчик була. Ленинград блокадасы беткәнче Ленинградны саклауда катнаша. Ике тапкыр яраланып, Вологда больницасында ятып чыга. Ленинград блокадасы өзелгәч, хат язып җибәрә: “ Бер зур елганы чыктык, икенче елганы чыксак – Берлин. Үземне бик зурладылар әле, “Кызыл йолдыз” ордены бирделәр, бәлки сезгә кирәге чыгар” , - дип орденның документын һәм Кызылармеец книжкасын җибәрә.

Ленинград блокадасыннан чыккач, тагы больницага эләгә һәм бик нык сызлануы турында  яза. Больницадан  чыккач  аны  алты айга өйгә җибәрергә приказ була. Бабай үзенең хатында: “Приказ килгәч уйсларны шундук кайтарып җибәрделәр, безне иртәнгә калдырдылар. Иртәнгә приказ алышынып , мине өйгә түгел , алты айга укырга җибәрергә булдылар” ,-  дип яза. Һәм елга кичкәндә дә взвод командиры чагы була.

“Кызыл Йолдыз” ордены алу турындагы хаты бабайның соңгы хаты була. 1945 елның  11 февралендә җиңү көненә 3 ай кала ул вафат була. Аның семьясына  геройларча вафат булды, дигән кара кәгазь  генә килеп ирешә. Калининград өлкәсендә җирләнә.

Ике бабамның да исемнәре Урыссу мәйданында  Хәтер тактасына уелып язылган.

Тузанлы юллардан үттеләр

Дөньяны күрмәгән балалар.